ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2020 г. с. Муслюмово № 174

**Мөслим муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында.**

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның баланслы туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатыннан, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 37 ст. үтәү йөзеннән, 213н номерлы Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш Министрлыгы Боерыгы, «Белем бирү учреждениеләре укучылары һәм тәрбияләнүчеләренең туклануын оештыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2012 елның 11 мартындагы 178 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2020 елга айлык һәм башка төр түләүләр турында» 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1. Мөслим муниципаль районының урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучыларны көненә ике тапкыр кайнар ризык белән, башлангыч һәм төп гомуми белем бирү мәктәпләрен кайнар төшке аш белән тукландыруны 7 сум 70 тиен (җиде сум җитмеш тиен) субсидия һәм һәр уку көненә ата – аналар түләвеннән оештырырга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

– урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучы бер балага балансланган иртәнге аш бәясен 20 сум күләмендә;

– бер укучыга көненә баланслы төшке аш бәясен 25 сум күләмендә;

– башлангыч һәм төп гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучы балага көненә балансланган төшке аш бәясен 25 сум күләмендә.

3. Белем бирү учреждениесендә туклануны оештыру һәм түләү процессы белән бәйле операцияләрне исәпкә алу өчен автоматлаштырылган AVSU.RU (AVSU.RU системасы) – ЭВМ һәм мәгълүматлар базалары Үзәге программасы исәпкә алу системасын кулланырга.

4. Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 150 ст. нигезендә күпбалалы гаиләләр һәм «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аз керемле дип танылган гаиләләр өчен 7 сум 70 тиен (җиде сум җитмеш тиен) күләмендә түләүсез кайнар ашлар оештырырга.

5. «ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Р. Т. Демидовка:

5.1. Укучыларның кайнар ашын оештыруга бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

5.2. Витаминнар һәм микроэлементлар белән баетылган төп туклыклы матдәләрнең эчтәлеге буенча балансланган иртәнге һәм төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын тикшереп торуны тәэмин итәргә;

5.3. Мәктәп яны участоклары продукциясе хисабына мәктәп ашханәләре ассортиментын баету эшен көчәйтергә;

5.4. Гомуми белем бирү оешмаларына продуктларның өзлексез керүен координацияләүне һәм контрольда тотуны тәэмин итәргә.

6. Мәктәп укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыручы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

6.1. Мәктәп ашханәләрен сыйфатлы азык-төлек белән өзлексез тәэмин итәргә.

6.2. Гамәлдәге санитар нормалар һәм кагыйдәләр нигезендә, гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруга производство контроле үткәрергә.

7. Мөслим муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУга (Н.А. Бубекова) гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен уку вакытында туклануны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тормышка ашырырга тәкъдим итәргә.

8. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 августындагы 456 номерлы карары, 2020 елның 24 гыйнварындагы 39 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

9. Әлеге караның үтәлешен контрольда тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р.А. Ильясов**